МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

№ ___697/о_______

ПРИКАЗ　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　Б О Е Р Ы К

«__02___»_______06_______2025__

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районында урнашкан «Әлмәт шәһәрендәге перинаталь үзәк» объекты территориясен ызанлау проектын раслау турында

Территориянең тотрыклы үсешен тәэмин итү максатларында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 42, 43, 45 һәм 46 статьялары, «Шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» 2023 елның 23 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022, 2023, 2024 һәм 2025 елларда территорияне планлаштыру проектларын, территорияне ызанлау проектларын раслау һәм күрсәтелгән проектларга иҗтимагый фикер алышулар яисә гавами тыңлаулар уздырмыйча гына үзгәрешләр кертү очракларын билгеләү турында» 2022 елның 27 июлендәге 722 номерлы карары, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районында урнашкан «Әлмәт шәһәрендәге перинаталь үзәк» объекты территориясен ызанлау проектын әзерләү турында» 2024 елның 12 декабрендәге 710/о номерлы боерыгы нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районында урнашкан «Әлмәт шәһәрендәге перинаталь үзәк» объекты территориясен ызанлау проектын расларга.

2. Территорияләрне үстерү департаментының Агломерацияләрне үстерү идарәсенең Әлмәт агломерациясен үстерү бүлегенә (О.М.Минһаҗетдиновага) түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенә ул үз көченә кергән көннән җиде календарь көннән дә соңга калмыйча җибәрүне;

әлеге боерыкны үз көченә кергән көннән җиде календарь көннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыруны;

әлеге боерыкны «Татарстан Республикасы шәһәр төзелеше эшчәнлеген мәгълүмати тәэмин итү» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасында ул басылып чыккан көннән алып 10 эш көне эчендә урнаштыруны.

3. Юридик бүлеккә (Р.И.Кузьминга), дәүләт теркәвенә алу өчен, әлеге боерыкның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин итәргә.

4. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

5. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны Территорияләрне үстерү департаментының Агломерацияләрне үстерү идарәсе башлыгы С.А.Рыбаковка йөкләргә.

Министр урынбасары В.Н.Кудряшев

МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА һәМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫК МИНИСТРЛЫГЫ
Отдел контроля исполнения документов

Татарстан Республикасы
Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 02.06.2025 ел, №_697/о боерыгы белән расланды

# Әлмәт муниципаль районында урнашкан «Әлмәт шәһәрендәге перинаталь үзәк» объекты территориясен ызанлау проекты

| Бүлек номеры | Атамасы | Искәрмә |
|---|---|---|
| 1 | 1 том. Территорияне ызанлау проекты. Текст өлеше. | |
| | 1 том. Территорияне ызанлау проекты. График өлеше | |
| 2 | 2 том. Территорияне ызанлау проектын нигезләү материаллары. График өлеше | китерелми |

# Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районында урнашкан «Әлмәт шәһәрендәге перинаталь үзәк»

1 том. Территорияне ызанлау проекты
Текст өлеше

2025

# Эчтәлек


| Бүлек | Атамасы | Бит |
|---|---|---|
| 1 | Барлыкка килә торган җир кишәрлекләренең мәйданы, шул исәптән аларны булдыруның мөмкин булган ысуллары турында исемлек һәм белешмәләр | 3 |
| 2 | Гомуми файдаланудагы территорияләргә яисә гомуми файдаланудагы мөлкәткә кертеләчәк, шул исәптән дәүләт яисә муниципаль ихтыяҗлар өчен резервлау һәм (яисә) тартып алу күздә тотыла торган барлыкка килә торган җир кишәрлекләренең мәйданы турында исемлек һәм белешмәләр | 4 |
| 3 | Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында каралган очракларда территорияне планлаштыру проекты нигезендә барлыкка килә торган җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төре | 4 |
| 4 | Урманнарның максатчан билгеләнеше, урман кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану төре (төрләре), урман кишәрлегенең сан һәм сыйфат характеристикалары, урман кишәрлегенең урманнарның махсус саклау кишәрлекләре чикләрендә урнашуы турында белешмәләр (территорияне ызманлау проектын әзерләү барлыкка килә торган һәм (яисә) үзгәртелә торган урман кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын билгеләү максатларында гамәлгә ашырылган очракта) | 4 |
| 5 | Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына кертү өчен кулланыла торган, аңа карата ызанлау проекты расланган территория чикләре турында координаталар системасында бу чикләрнең характерлы нокталары координаталары исемлеге булган белешмәләр Ызанлау проекты расланган территория чикләренең характерлы нокталары координаталары Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә территориаль зоналар өчен билгеләнгән чикләрнең характерлы нокталары координаталарын төгәл билгеләү таләпләре нигезендә билгеләнә | китерелми |

| т/с | Башлангыч җир кишәрлегенең кадастр (шартлы) номеры/Кадастр кварталы номеры | Барлыкка килә торган җир кишәрлегенең шартлы номеры | Барлыкка килә торган җир кишәрлегенең мәйданы, кв. м. | Җир кишәрлеген барлыкка китерү ысулы | Башлангыч җир кишәрлегенең адресы | Җир категориясе/Башлангыч җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану төре | Барлыкка килгән җир кишәрлегенә җир категориясен/рөхсәт ителгән файдалану төрен (классификатор коды) билгеләргә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| 1 | 16:45:010119:883 | ЗУ1 | 195 | Башлангыч һәм дәүләт милке чикләнмәгән җирләрне яңадан бүлү юлы белән җир кишәрлеге барлыкка китерү | Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Әлмәт муниципаль районы, Әлмәт шәһәре, 51 кв., 1 | Торак пункт җирләре/ Амбулатор-поликлиника хезмәте күрсәтү, Стационар медицина хезмәте күрсәтү | Торак пунктлар җирләре/ Амбулатор-поликлиника хезмәте күрсәтү, Стационар медицина хезмәте күрсәтү (кодлар 3.4.1, 3.4.2) |
| | 16:45:010119 | | | | | Җир категориясе билгеләнмәгән/Рөхсәт ителгән файдалану төре билгеләнмәгән | |
| 2 | ЗУ1 | ЗУ2 | 38299 | Башлангыч җир кишәрлекләрен берләштерү юлы белән җир кишәрлеге барлыкка китерү | Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Әлмәт муниципаль районы, Әлмәт шәһәре | Торак пункт җирләре/ Амбулатор-поликлиника хезмәте күрсәтү, Стационар медицина хезмәте күрсәтү | Торак пунктлар җирләре/ Амбулатор-поликлиника хезмәте күрсәтү, Стационар медицина хезмәте күрсәтү (кодлар 3.4.1, 3.4.2) |
| | 16:45:010119:1194 | | | | Татарстан Республикасы, Әлмәт муниципаль районы, «Әлмәт» муниципаль берәмлеге, Әлмәт шәһәре, Радищев ур., 67 й. | Торак пункт җирләре / «Татнефть» ААҖ медсанчасть бинасы астына | |
| | 16:45:010119:900 | | | | Татарстан Республикасы, Әлмәт муниципаль районы, Әлмәт шәһәре, 41 кв., 2 нче гараж | Торак пункт җирләре/ Амбулатор-поликлиника хезмәте күрсәтү, Стационар медицина хезмәте күрсәтү | |

1. Барлыкка килә торган җир кишәрлекләренең мәйданы, шул исәптән аларны булдыруның мөмкин булган ысуллары турында исемлек һәм белешмәләр

1.1 нче таблица.

2. Гомуми файдаланудагы территорияләргә яисә гомуми файдаланудагы мөлкәткә кертеләчәк, шул исәптән дәүләт яисә муниципаль ихтыяҗлар өчен резервлау һәм (яисә) тартып алу күздә тотыла торган барлыкка килә торган җир кишәрлекләренең мәйданы турында исемлек һәм белешмәләр

Территорияне ызанлау проектында гомуми файдаланудагы территорияләргә яисә гомуми файдаланудагы мөлкәткә кертеләчәк, шул исәптән дәүләт яисә муниципаль ихтыяҗлары өчен резервлау һәм (яисә) тартып алу күздә тотыла торган җир кишәрлекләре төзү каралмый.

3. Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында каралган очракларда территорияне планлаштыру проекты нигезендә барлыкка килә торган җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төре

Территорияне ызанлау проекты эшләнгән территория чикләрендә территорияне планлаштыру проекты эшләнмәгән һәм расланмаган.

4. Урманнарның максатчан билгеләнеше, урман кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану төре (төрләре), урман кишәрлегенең сан һәм сыйфат характеристикалары, урман кишәрлегенең урманнарның махсус саклау кишәрлекләре чикләрендә урнашуы турында белешмәләр (территорияне ызманлау проектын әзерләү барлыкка килә торган һәм (яисә) үзгәртелә торган урман кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын билгеләү максатларында гамәлгә ашырылган очракта)

Территорияне ызанлау проекты эшләнгән территория чикләрендә урман кишәрлекләре юк, шуңа күрә әлеге бүлек әлеге проектта эшләнми.

5. Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына кертү өчен кулланыла торган, аңа карата ызанлау проекты расланган территория чикләре турында координаталар системасында бу чикләрнең характерлы нокталары координаталары исемлеге булган белешмәләр Ызанлау проекты расланган территория чикләренең характерлы нокталары координаталары Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә территориаль зоналар өчен билгеләнгән чикләрнең характерлы нокталары координаталарын төгәл билгеләү таләпләре нигезендә билгеләнә (китерелми)


# Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районында урнашкан «Әлмәт шәһәрендәге перинаталь үзәк»

1 том. Территорияне ызанлау проекты
График өлеше

2025

Перв. примен.

Справ. №




Условные обозначения:

границы земельных участков

границы территории в отношении которой осуществляется подготовка проекта межевания территории

образуемый земельный участок

Подп. и дата

Инв. N дубл.

Взам. инв. №

Подп. и дата

Инв. № подл.


| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | № 06-ПМТ/2024 |
| Изм | Лист | № докум. | Подп. | Дата | Проект межевания территории объекта "Перинатальный центр в г.Альметьевск", расположенного в Альметьеском муниципальном районе Республики Татарстан |
| Разраб. | | Акимова Т.А. | | | |
| Пров. | | Мордангулова Р.Р. | | | Основная часть. Чертеж земельных участков, образуемых на 1 этапе |
| Утв. | | Зайцева | | | |
| | | | | 2024 | М 1:2000 |

| стадия | Лист | Листов |
|---|---|---|
| ПМТ | 9 | 13 |

АО "БТИ РТ"

Копировал

Формат А4




Условные обозначения:

- границы земельных участков
- границы территории в отношении которой осуществляется подготовка проекта межевания территории
- образуемый земельный участок

| Изм | Лист | №докум. | Подп. | Дата | № 06-ПМТ/2024 | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Разраб. | | Акимова Т.А. | | | Проект межевания территории объекта "Перинатальный центр в г.Альметьевск", расположенного в Альметьевском муниципальном районе Республики Татарстан | | |
| Пров. | | Мордагулова Р.Р. | | | Основная часть. Чертеж земельных участков, образуемых на 2 этапе | стадия | Лист | Листов |
| Утв. | | Хаттева [illegible] | | | | ПМТ | 10 | 13 |
| | | | | 2024 | М 1:2000 | АО "БТИ РТ" | | |

Перв. примен.
Справ. №
Подп. и дата
Инв. N дубл.
Взам. инв. №
Подп. и дата
Инв. № подп.

Копировал
Формат А4